РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
Глава Асеевского сельского поселения Азнакаевского муниципального района
ул. Центральная, д.38Б, с. Асеево, Азнакаевский район, 423310

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
Азнакай муниципаль районы Әсәй авыл җирлеге Башлыгы
Үзәк ур., 38Б нче йорт, Әсәй авылы, Азнакай районы, 423310

Тел./факс(885592)43-2-37, 43-3-27; E-mail: Asv.Azn@tatar.ru; http://aznakayevo.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«03» ноябрь 2022 ел № 5

Азнакай муниципаль районы «Әсәй авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында проект буенча ачык тыңлаулар билгеләү хакында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 31 статьясф, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 28 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль берәмлегенең «Әсәй авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставы, Азнакай муниципаль районы Әсәй авыл җирлегендә ачык тыңлаулар оештыру һәм уздыру тәртибе турындагы нигезләмәгә таянып, карар итәм:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әсәй авыл җирлеге Советының 2014 елның 18 февралендәге 84-48нче номерлы карары белән расланган, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Әсәй авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү проектны (2016 елның 30 ноябрендәге 45нче, 2017 елның 4 сентябрендәге 13нче, 2020 елның 10 мартындагы 35нче, 2021 елның 11 августындагы 31-17нче номерлы карарлар редакциясендә) буенча ачык тыңлаулар билгеләргә (1 нче кушымта).

2. Билгеләргә:

- ачык тыңлауларны оештыручыны Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әсәй авыл җирлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү пректын әзерләү комиссиясен;
- уздыру вакыты – 2022 елның 03 ноябреннән 2022 елның 01 декабренә 17 сәгатьтән 18 сәгатькадәр;
- уздыру урыны: Әсәй авылы, Үзәк ур. , 38Г й.;
- тикшерелгән мәсьәлә буенча язма тәкъдимнәр һәм искәрмәләр кертелә ала торган адрес: Әсәй авылы, Үзәк ур., 38Б й. , Азнакай муниципаль районы Әсәй

авыл җирлеге башкарма комитеты.

4. Азнакай муниципаль районы Әсәй  авыл җирлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү профектын әзерләү комиссиясенә тәкъдим итәргә:

- гамәлдәге законнар нигезендә һәм әлеге карарда билгеләнгән срокларда Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Әсәй  авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турындагы проект буенча ачык тыңлаулар әзерләргә һәм үткәрергә;

- ачык тыңлауларны уздыру нәтиҗәләре турында бәяләмә әзерләргә һәм аны билгеләнгән тәртиптә игълан итәргә;

- Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Әсәй  авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында проектны Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Әсәй авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында түбәндәге веб-адрес буенча урнаштырырга: http://aznakaevo.tatar.ru/.

5. Әлеге карарны «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы»нда урнаштыру юлы белән игълан итәргә: http://pravo.tatarstan.ru һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга: http//aznakayevo.tatar.ru/.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Башлык З.Ә. Идрисов.

Республики Татарстан
Азнакай муниципаль районы Әсәй авыл
җирлеге башлыгы карарына 1 нче
кушымта
03.11. 2022 ел №5

**Азнакай муниципаль районы**
**Әсәй авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

Әсәй авылы №____ «___» _________ 2022 г.

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әсәй авыл җирлеге Советының 2014 елның 18 февралендәге 84-48нче номерлы карары белән расланган, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Әсәй авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү проектны әзерләү хакында (2016 елның 30 ноябрендәге 45нче, 2017 елның 4 сентябрендәге 13нче, 2020 елның 10 мартындагы 35нче, 2021 елның 11 августындагы 31-17нче номерлы карарлар редакциясендә)

Муниципаль норматив хокукый актларны Россия Федерациясенең гамәлдәге шәһәр төзелеше кодексына туры китерү максатларында һәм «Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына һәм Россия Федерациясенең 2022 елның 14 июлендәге 350-ФЗ номерлы «Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында” Федераль законны үтәү йөзеннән

Әсәй авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әсәй авыл җирлеге Советының 2014 елның 18 февралендәге 84-48нче номерлы карары белән расланган, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Әсәй авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә (2016 елның 30 ноябрендәге 45нче, 2017 елның 4 сентябрендәге 13нче, 2020 елның 10 мартындагы 35нче, 2021 елның 11 августындагы 31-17нче номерлы карарлар редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 25 статьяның 2 өлешендәге 4 пунктны «, Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнә торган критерийлардан» сүзләрен өстәргә.

2. Әлеге карарны«Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы»нда түбәндәге веб-адрес буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә: http://pravo.tatarstan.ru һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында: http//aznakayevo.tatar.ru.//

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әсәй авыл җирлеге Советының торак-коммуналь хуҗалык, төзекләндерү, экология һәм җир мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Рәис